РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

01.11.2024 №17

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 19.08.2016 №23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" 24.10.2022 елда №1885 карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында»гы 19.08.2016 елда №23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Оешма җитәкчесе янгынга каршы ишекләрне, шулай ук ишек тоткаларын, "антипаник " йозак җайланмаларын, җитештерүче тарафыннан каралган тыгызлауларны һәм ишек бусагаларын, ә баскыч мәйданчыклары ишекләрендә, эвакуацион чыгу ишекләрендә, шул исәптән подвалдан беренче катка алып баручы ишекләрдә (фатирларга, коридорларга, вестибюльләргә (фойе) һәм турыдан-туры тышка алып баручы ишекләрдән тыш) үз-үзен ябу җайланмаларының булуын һәм төзеклеген тәэмин итә;

1.2. 3.2 пунктта түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:
"Янгынга каршы яки төтенгә каршы ишекләрне (җайланмаларны) нормаль ябуга комачаулый торган нинди дә булса җайланмалар урнаштыру рөхсәт ителми.»;

1.3. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.2. Эвакуация юлларындагы ишекләр, янгын куркынычсызлыгы норматив документлары таләпләре буенча ачылмый торган ишекләрдән тыш, бинадан чыгу юнәлешендә дә иректе ачылырга тиеш.

Катлы коридорлардан, холллардан, фойелардан, вестибюльләрдән, баскыч мәйданчыкларыннан, зал бүлмәләреннән эвакуацион чыгу ишекләрендәге бикләр(йозаклар), биналарны карап тотуның (саклау, иминлекне тәэмин итүнең) махсус режимы билгеләнгән саклау объектларыннан тыш, аларны эчтән ачкычсыз иректе ачу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Биналарны карап тотуның (саклауның, иминлекне тәэмин итүнең) махсус режимы билгеләнгән, мондый биналарның ишекләрен эчтән ачарга мөмкинлек

бирми торган саклау объектлары өчен бинаның янгыннан саклау системалары сигналы буенча һәм (яисә) тәүлек буе сак белән шөгыльләнүче хезмәткәр (эшче) тарафыннан эвакуацион чыгу ишекләренең бикләрен автомат рәвештә ачу тәэмин ителергә тиеш.»;

1.4. 5.12 пунктының икенче җөмләсендә. "янгын щитларының кирәкле саны һәм аларның тибы билгеләнә" сүзләрен «янгын щитларының тибы билгеләнә " сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 5.13 пункт һәм 5.14 пунктны юкка чыгарырга;

1.6. 5.15 пунктны 5.13 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы Д.М.Гайнетдинов